**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**«ИСКЕ АБДУЛ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»**
**МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ СОВЕТЫ**

# КАРАР

«29» июнь 2019 ел Иске Абдул авылы № 6/1

**«Авыл җирлегенең аерым сорауларын хәл итү буенча вәкаләтләрне (вәкаләтләр өлешен) тапшыру турында»**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплар турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ санлы Федераль закон, Росси Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгының «Җирле үзидарә органнар тарафыннан муниципаль милек реестрларын алып бару тәртибен раслау турында 2011 елның 30 августындагы 424 санлы приказы, Татарстан Республикасы Тука муниципаль районы «Иске Абдул авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставы нигезендә Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Иске Абдул авы җирлеге Советы

**КАРАР БИРДЕ**:

1. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Советына Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Иске Абдул авыл җирлеге Башкарма комитетының җирле әһәмияттәге мәсьәләнең бер өлешен хәл итү буенча түбәндәге вәкаләтләрен Тукай муниципаль районы Башкарма комитетына тапшыру турында мәсьәләне карарга тәкъдим итәргә:

– авыл җирлегенең муниципаль милегендә булган мөлкәт реестрын алып бару;

– Иске Абдул авыл җирлегенең муниципаль казнасын алып бару.

2. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Советы тарафыннан әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән тәкъдим кабул ителгән очракта, Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Иске Абдул авыл җирлеге Башкарма комитетына:

– әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән вәкаләтләрне тапшыру турында килешү төзергә.

3. Әлеге карарны авыл җирлегенең рәсми стендларында урнаштырып, халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының рәсми сайтында «авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга.

5. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Иске Абдул авыл җирлеге Башлыгына йөкләргә.

Иске Абдул авыл җирлеге башлыгы,
Совет Рәисе Р.Х.Сафина